**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"22" ноябрь 2020 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 22 ноябрендә «Сез 2021 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Җирле автомобиль юлларында юл эшләре өчен: Бахтияр авылында юлларны төзекләндерү һәм төзү өчен хезмәтләргә түләү, төзелеш материаллары алу.

2. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү: Бахтияр авылы сулыгы ярында су алу мәйданчыгы урнаштыру өчен хезмәтләргә түләү, төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 154 (йөз илле дүрт) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 96 (туксан алты) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 96 (туксан алты) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. "Сез 2021 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирле автомобиль юлларында юл эшләре өчен: Бахтияр авылында юлларны төзекләндерү һәм төзү өчен хезмәтләргә түләү, төзелеш материаллары алу"
мәсьәләсен кабул итәргә.
2) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү: Бахтияр авылы сулыгы ярында су алу мәйданчыгы урнаштыру өчен хезмәтләргә түләү, төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http;//pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Тахавиев Ф.К.